**Г.Нәбиуллина, Ю. Хисияма**
*Казанский федеральный университет, г. Казань*

# ТАТАР ПАРЕМИЯЛӘРЕ КОНТЕКСТЫНДА ТАРТЫМ КУШЫМЧАСЫ

*В данной статье рассматривается категория принадлежности в контексте татарских паремий.*

*подлежащее, пословица, окончание принадлежности.*

*In article the category of accessory in the context of the Tatar paremias is considered.*

*subject, proverb, termination of accessory.*

Тел тарихын өйрәнүче галимнәр баш җөмләдәге грамматик иянең тартым күрсәткече алуын бик тирәннән — кушма җөмләләрнең формалашу, үсеш-үзгәреш процессы белән бәйләп аңлаталар. Тартым кушымчасы нигезендә бәйләнгән мәкальләр телебездә бик борынгыдан ук формалашып җиткән һәм гомумхалык телендә продуктив булган синтаксик калыпларга нигезләнеп төзеләләр. Бу төзелмәләр структур яктан гына түгел, семантик яктан да калыплашуга, типиклашуга омтылалар — алар катгый хөкемне, үткен фикерне формалаштыру өчен нигез булган тотрыклы калыпларны чагылдыралар.

1. Каршы кую мөнәсәбәтендәге мәкальләрдә грамматик ияләре тартым күрсәткече алган берәмлекләр аерым урын били: а) ияләр III зат тартым кушымчасы алалар: *Теле оста, кулы кыска (1370); Эше каты, икмәге татлы (1361); Төтене күп, ялкыны аз (2576); Ирене татлы, җаны ачы (9367);* ә) ияләр I зат тартым кушымчасы алалар: *Эчем ялкын, тышым салкын (1493); Кулым кара, йөзем ак (25647); Атым ирле, буем ярлы (10463);* б) аерым очракларда II зат тартым кушымчасы алуы күзәтелә: *Беләзегең алтын, йөрәгең салкын (10855).* Тартым күрсәткече икенче компонентта гына килергә мөмкин: *Дус күп, турысы аз (20799); Гәүһәр кечкенә, бәясе зур (2465); Ат олы, ашъяулыгы коры (15996).* Күргәнебезчә, бу очракта тартым күрсәткече каршы кую мөнәсәбәтенә кискенрәк төсмер өстәүче грамматик чара ролендә килә.

Икенче компоненттагы грамматик иянең III зат тартым күрсәткече алуы нәтиҗәсендә каршы кую ныгый, кискенләшә төшә: *Үрдәк йомыркасын тавык басар, бәбкәсе суга качар (4416); Дөнья үтәр дә китәр, калганы безгә җитәр (18728); Исле чәчәк өзелер, болында исе калыр (7540); Тукран тәүбә итәр, тәүбәсе кырын китәр (4205); Усак агачы шарт-шорт атар, җылысы булмас(3333).*

2. Номинатив төзелмәләр бәйләнешендәге мәкальләрдә бигрәк тә иялек килешендәге сүзләр белән җәенкеләнеп килгән номинатив калыплар продуктив. Баш кисәкләр, кагыйдә буларак, III зат тартым кушымчасы алалар. Җәенкеләндерүче кисәк төрле сүз төркемнәре белән белдерелә: а) еш кына исем белән бирелә: *Филнең теше, останың эше (581); Егетләрнең асылы, арысланнарның нәселе (33754); Яшьләрнең кулы, картларның теле (18525);* б) исемләшкән сыйфатлар килә: *Яманның каргышы, яхшының алкышы (33122); Биләнкенең биле, юбалгының аягы (3726); Борынгының төлкесе, бүгенгенең көлкесе (4781);* в) сирәгрәк исемләшкән сыйфат фигыльләр килә: *Сөйгәннең колы, сөймәгәннең солтаны (9265)*; г) кайбер очракларда алмашлыклар кулланыла: *Берәүнең куесы, берәүнең сыегы (14874).*

3. Мәкальләрдәге иярчен җөмләнең грамматик иясе еш кына тартым кушымчасы ала. Тартым формасы бирүдә гаять әһәмиятле роль уйный. Ул иярчен җөмләнең иясе белән баш җөмләдәге ияртүче сүз арасында каратылу мөнәсәбәте урнаштыра, ияртүче сүзгә өстәмә конкретлык, билгелелек төсмере өсти, шул рәвешле иярчен җөмләнең баш җөмләгә структур һәм семантик бәйләнешен ныгыта. Тартым формасы иярчен җөмләнең иясе белән баш җөмләдәге ияртүче сүз арасында эчке мәгънәви-структур бәйләнеш урнаштыра, иярчен җөмләнең җөмләлек табигатен ныгытып килә. Мәсәлән, С.А.Соколов тартым кушымчасын өстәмә синтаксик чара итеп карый һәм ияртүле бәйләнешне белдерү өчен кулланыла башлаган дип аңлата [2]. Н.К.Дмитриев та шундыйрак караштa тора һәм бу күренешне язма әдәби телнең үсеше белән бәйләп күрсәтә [3: 253-254].

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, иярчен җөмләдәге грамматик иянең тартым күрсәткече алуы хәбәре -ган формалы иярчен җөмләләр формалашуда хәлиткеч роль уйный. Хәбәре -ган формасындагы иярчен җөмләләрнең бер өлеше *иярчен ия җөмләләр* булып формалашалар. Биредә иярчен ия җөмләләрдә грамматик иянең тартым күрсәткече алуы тагын да активлашкан Мәсәлән, *Акчасы булган сакланыр (23078); Агай орган авыртмас (12572); Үзе белгән хур булмый (30546); Кызы булган тиз картаер (8304); Күршесенә өмете булган шәмсез ятар (20626).* Иярчен ия җөмләләрдә, ягъни компонентлар арасында субъект мөнәсәбәте урнашканда, тартым кушымчасының роле тагын да көчәя. Биредә аергыч функциясен үтәүче иярчен җөмләне ияртеп килә торган сүз үзеннән-үзе аңлашыла торган сүз буларак төшеп кала. Мондый җөмләләрне икенче төрле суперсинтетик кушма җөмләләр дип тә атыйлар һәм аларның гади җөмләгә якын торуларын аңлаталар.

Тамырлары бик борынгы төрки чорларга барып тоташкан мондый төзелмәләрнең мәкальләрдә еш кына фразеологиклашкан төрләрен очратырга мөмкин. Мәсәлән, *Җаны теләгән җылан ите ашаган (16113); Яхшылыгы тимәгән дусның яманлыгыннан саклан (20945)* мәкальләрендә *җаны теләгән, яхшылыгы тимәгән* кебек ия һәм хәбәр бәйләнешендә килгән сүзләр хәзерге телдә тотрыклы сүзтезмәләр булып йөриләр. Бу төзелмәләрнең кайберләре үзләрендәге җөмләлек табигатен тулысынча җуйганнар, кайберләре исә үзләренең җөмләлекләрен өлешчә саклыйлар. Мондый лексикалашкан вариантлар сөйләм телендә дә, фольклор әсәрләрендә дә еш очрыйлар. Әлеге күренеш аларның бик борынгыдан кулланылып килүләрен раслый.

Җыйнак структурага нигезләнгән иярчен җөмләләр дә табылды: *Дәрте юк — күсәк (8383); Аты бар — арслан (34118).* Галимнәр мондый типтагы җөмләләрнең бик борынгыдан килүләрен искәртеп, аларны (мәсәлән, Э.В.Севортян *Баласы бар әйел* җөмләсен китерә) синтаксик яктан катнаш, ягъни атрибутив-предикатив конструкцияләр итеп билгеләү дөресрәк булыр дип аңлаталар [4: 134].

Мәкальләрдә шунысы ачык күренә: иярчен җөмләнең грамматик иясе һәр очракта да III зат тартым күрсәткече ала. Тартым формасы иярчен җөмләнең иясе белән баш җөмләдәге ияртүче сүз арасында эчке мәгънәви-структур бәйләнеш урнаштыра, иярчен җөмләнең җөмләлек табигатен ныгытып килә. Тюркологлар бик борынгыдан килә торган мондый төзелмәләрдә тартым күрсәткеченең әһәмиятле роль уйнавын күрсәтәләр. Кайбер галимнәр, мәсәлән, Н.К.Дмитриев аларны иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртеп килүче бәйләүче чара итеп карау ягында тора [3: 255].

4. Хәбәре сыйфат һәм рәвеш белән бирелгән иярчен җөмләләрнең билгеле бер дәрәҗәдә урын табуы мәкальләрнең тел тарихын, аның грамматик төзелешен саклап килүче хәзинә булуын күрсәтә. Мондый мәкалләрдә тә тартым кушымчасы актив кулланыла.

1) Янәшә торып бәйләнгән иярчен җөмләләрнең кайберләре *синтетик ия җөмләләр* булып киләләр: *Йөзе ямьсез көзгене яманлар (8620); Нәфесе яман бугазыннан эленер (16279); Карыны ач казанга карар (15950); Туышы яман туганын яманлар (13032); Үзе яман туганын яманлар (13096).*

2) Иярчен җөмләләр баш җөмләгә иялек килеше кушымчасы аша бәйләнеп, *иярчен аергыч җөмләләр* булып формалашалар. Биредә җыйнак структураларга нигезләнгән мәкальләр аерым урын алып торалар. Мәсәлән, *Баласы күпнең бәласы күп (11969); Ашы тизнең эше тиз (1295); Казаны башканың кайгысы башка (14799); Ирләре татуның иле тату (21627); Акчасы акның йөзе ак (23076); Юлы уңның эше уң (22126); Күңеле киңнең дөньясы киң (35615); Җире байның иле бай (7126); Эше акның йөзе ак (35015).* Биредә хәбәрләрнең кабатланып килүе, грамматик ияләрнең тартым күрсәткече алуы компонентлар арасындагы структур-семантик һәм ритмик бәйләнешне ныгыта.

3) Синтетик җөмләләр баш җөмләгә төшем килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнеп киләләр. Алар *иярчен тәмамлык җөмләләр* булып формалашалар һәм, гадәттә, җыйнак җөмлә калыпларына нигезләнеп төзеләләр: *Туны яманны эт каба (4995); Итәге яманны эт кабар (4946);*

*Дусы күпне яу алмый (20802); Кулы бәйлене кем дә кыйнар (26784); Киеме яманны эт кабар (14005); Юлдашы яманны яу алыр (22168).*

Биредә җыйнак структураларга нигезләнгән мәкальләр аерым урын алып торалар. Мәсәлән, *Баласы күпнең бәласы күп (11969); Ашы тизнең эше тиз (1295); Туышы бернең куышы бер (13091); Казаны башканың кайгысы башка (14799); Ирләре татуның иле тату (21627); Акчасы акның йөзе ак (23076); Юлы уңның эше уң (22126); Күңеле киңнең дөньясы киң (35615); Җире байның иле бай (7126); Эше акның йөзе ак (35015).* Биредә хәбәрләрнең кабатланып килүе, грамматик ияләрнең тартым күрсәткече алуы компонентлар арасындагы структур-семантик һәм ритмик бәйләнешне ныгыта.

5. Хәбәре кире шарт фигыль белән бирелгән иярчен җөмләле мәкальләрдә дә *антонимнар* белән берлектә *тартым кушымчасы* мөһим роль уйный: *Җиңәм яман булса да, агам яхшы (14208); Морҗаң кәкре булса да, төтенең туры булсын (13438); Ярлы бай артыннан күпме йөрсә дә, өсте-башы бөтәймәс (25512); Арслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче бар (4598); Җитмеш йолдыз туса да, яктылыгы айдай юк (1952); Гыйлемнең тамыры ачы булса да, җимеше татлы (29979).* Мисаллардан аңлашылганча, бу төзелмәләрдә грамматик кисәкләр, аеруча ияләр II яисә III зат тартым кушымчасы алалар.

6. Шундый мөнәсәбәтле сүзе ярдәмендә бәйләнгән мәкальләр дә, нигездә, бер структур калып үрнәгендә төзеләләр: компонентлар уртак төзелешкә корылып, грамматик ияләре III зат яисә II зат тартым формасында киләләр. Мәсәлән, *Агачы нинди, җимеше шундый (7417); Анасы нинди, кызы шундый (8936); Учагы нинди, ялкыны шундый (13469); Асылы нинди, нәселе шундый (13114); Нәселе нинди, баласы шундый (12491); Дусың нинди, кадерең шундый (20817); Үзең нинди, көзгең шундый (35333). Җирең нинди булса, көзгең шундый була (15354).*

7. Мәкальләрдә очраган –дагы/-дәге кушымчасының кулланылышы кызыклы: *Кулымдагын алмый торып, авызымдагын нигә бирәмен? (23558);*

*Уйнап әйткән уендагын әйткән (29227); Эт дуңгыз алдындагын ашарга да тарсынмый (6704); Алдагын алла белә (36147); Кыз кыясындагын куймас (8254).* Мондый форма, Ф.С. Баязитова тикшеренүләренә караганда, татар теленең Минзәлә сөйләшендә дә очрый. Аның фикеренчә, -гы/-ге кушымчалары үзләрендә тартым категориясе мәгънәсен саклыйлар [1: 67-83].

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, бик борынгыдан килә торган мәкальләр контекстында тартым кушымчасы киң кулланыла. Бигрәк тә кушма җөмләләр калыбындагы мәкальләрдә иярчен җөмләнең иясе III зат тартым кушымчасы алу нәтиҗәсендә компонентларның структур-семантик, ритмик бәйләнеше ныгый.

## Әдәбият

1. Баязитова Ф.С. Мензеленсикй говор татарского языка // Материалы по татарской диалектологии. – Казань,1989. – С. 67-83
2. Гаджиева Н.З., Серебрянников Б.А. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Синтаксис. – М., 1986. – 284 с.
3. Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. – М. – Л., 1948. – 207 с.
4. Севортян Э.В. О некоторых вопросах сложноподчиненного предложения в тюркских языках // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Синтаксис. – М.: Наука, 1961. – С. 122-134
5. Татар грамматикасы. 3 т. Т.1. - М.: Инсан; Казан: Фикер, 1999. – 510 б.
6. Юсупова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә., Денмөхәммәтова Э.Н., Мөгтәсимова Г.Р.Татар паремияләренең теле. – Казан: Ихлас, 2010. – 319 с.